Халык жыены карары

№ 1 17.10.2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге составына керүче Чубар-Абдул авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Сез 2021 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга гравий җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Чубар Абдул авылында Совет урамына:
- Чубар-Абдул авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 275 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 199 кеше кергән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 199 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы составына керүче Чубар-Абдул авыл җирлегендә узган халык җыенын халык җыенын утте дип танырга,
   халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.
2. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Чубар-Абдул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы

студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән:

- юлларга гравий җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Чубар Абдул авылында Совет урамына:
- Чубар-Абдул авылында («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне») бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, энергия саклаучы лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү.

3.Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чубар-Абдул авылы, Совет ур., 85 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче:
Чубар-Абдулавыл җирлеге башлыгы: Н.А. Фатхетдинов